Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучылар өчен татар әдәбиятыннан олимпиада биремнәренә якынча җаваплар (мәктәп туры, 2017-2018 уку елы). 8 нче сыйныф

Максималь балл – 41.

I. Теоретик биремнәр. (8 балл)

1. Мәгърифәтчелек әсәрләрендә төп конфликт кемнәр арасында барлыкка килә һәм ничек тәмамлана? (5 балл)

Надан һәм акыллы, белемле һәм белемсез яки тәрбияле, әхлаклы һәм тәрбиясез геройлар арасында барлыкка килә һәм акыллы, тәрбияле геройның җиңүе белән тәмамлана.

2. Түбәндә аталган әдипләрнең кайсылары XX йөз башында актив иҗат эше белән шөгыльләнә. (3 балл)

А) Мөхәммәдъяр
Б) **Г.Тукай**
В) К.Насыйри
Г) **Ш.Камал**
Д) **Н.Думави**

II. Әдәби әсәргә кагылышлы биремнәр. (18 балл)

1. Мөхәммәдъярның “Нәсыйхәт” шигырендә нинди символик образларга мөрәҗәгать ителә, санап чыгыгыз. (3 балл)

Былбыл, гөл, бакча.

2. Мөхәммәдъярның “Нәсыйхәт” шигырендә җиткерелгән төп идеяне ачыклап языгыз, укучыга нинди фикер әйтелә? (5 балл)

Дин, Көръән кушканча яшәгән очракта, кешенең юлы туры, акылы камил, тормыш-яшәеше имин булыр һ.б.

3. Мөхәммәдъярның “Нәсыйхәт” шигырендә суфичылык әдәбиятына хас нинди үзенчәлекләр чагылыш таба? (10 балл)

Үзәгендә илаһи мәхәббәт ята, тормыш – Алла оппозициясенә таяна, символик образлылыкка мөрәҗәгать итә, яшерен эчтәлек бар, әхлакны төзәтергә өнди һ.б.

III. Иҗади эш. (15 балл)

Соңгы елларда киң кулланылышта булган *компьютер, ноутбук, телефон, планшет, телевизор* турында 5 әйтем уйлап чыгарып языгыз.